383. Ташбака дип исемләнгән башкаручы компьютер экраны буйлап хәрәкәтләнә һәм артыннан сызык рәвешендә эз калдыра. Һәр конкрет вакыт аралыгында башкаручының торган урыны һәм хәрәкәтләнү юнәлеше билгеле. Башкаручы ике команда башкара ала:

**Алга n** (n – бөтен сан), Ташбаканы хәрәкәтләнү юнәлешендә n адымга атлата; **Уңга m** (m – бөтен сан), Ташбаканың хәрәкәтләнү юнәлешен сәгать теле уңаена (уңга) m градуска бора.

*Ташбакага башкару өчен түбәндәге алгоритм бирелгән:*

**Кабатла 5 [Алга 100 Уңга 60]**

Экранда нинди фигура барлыкка киләчәк?

1) төзек бишпочмак
2) төзек өчпочмак
3) төзек алтыпочмак
4) йомык булмаган сынык сызык

384. Бирелгән кайсы *X* кыйммәте өчен түбәндәге әйтем хак?

(*X* < 5) **ҺӘМ** (*X* < 4) **ТҮГЕЛ**?

1) 5
2) 2
3) 3
4) 4

385. Ташбака дип исемләнгән башкаручы компьютер экраны буйлап хәрәкәтләнә һәм артыннан сызык рәвешендә эз калдыра. Һәр конкрет вакыт аралыгында башкаручының торган урыны һәм хәрәкәтләнү юнәлеше билгеле. Башкаручы ике команда башкара ала:

**Алга n** (n – бөтен сан), Ташбаканы хәрәкәтләнү юнәлешендә n адымга атлата; **Уңга m** (m – бөтен сан), Ташбаканың хәрәкәтләнү юнәлешен сәгать теле уңаена (уңга) m градуска бора.

*Ташбакага башкару өчен түбәндәге алгоритм бирелгән:*

**Кабатла 5 [Алга 100 Уңга 120]**

Экранда нинди фигура барлыкка киләчәк?

1) төзек бишпочмак
2) төзек өчпочмак
3) төзек алтыпочмак
4) йомык булмаган сынык сызык

386. Компьютерда җыелган мәкалә 64 биттән тора, һәр биттә 40 юл, һәр юлда 64 символ бар. Һәр символ 8 бит белән кодлана торган КОИ-8 кодировкасында мәкаләнең мәгълүмати күләмен ачыклагыз.

1) 1280 байт
2) 160 Кбайт
3) 2560 байт
4) 320 Кбайт

387. Икешәрле санау системасындагы 1110001 санын унарлы санау системасына күчерегез.

388. Бүлүче дип исемләнгән башкаручы ике команда башкара белә, алар номерланган:

**1. 2 санына бүл**

**2. 3 санын ал**

Беренче команда экрандагы санны 2 тапкырга, икенче команда – 3 санына киметә. Башкаручы бары тик натураль саннар белән генә эш йөртә.

**34 санын 1 санына** үзгәртә ала торган, 5 командадан артмаган алгоритм төзегез. Җавапта бары тик команда номерларын гына языгыз.

*(Мәсәлән, 21211 – 33 санын 3 санына үзгәртә торган алгоритм:*

*3 санын ал*

*2 санына бүл*

*3 санын ал*

*2 санына бүл*

*2 санына бүл)*

Андый алгоритмнар берничә булса, аларның берәрсен сайлап алып языгыз.

389. Программада «:=» тамгасы – үзләштерү операторын, «+», «–», «*» и «/» тамгалары – бирелгән тәртиптә кушу, алу, тапкырлау һәм бүлү гамәлләрен аңлата. Операцияләр башкарылу кагыйдәләре һәм гамәлләр тәртибе арифметика кагыйдәләре белән туры килә.

Түбәндәге алгоритм башкарылганнан соң **b** үзгәрешлесенең кыйммәтен ачыклагыз:

a := 1

b := 4

a := 2*a+3*b

b := a/2*b

Җавапта бер бөтен сан – **b** үзгәрешлесенең кыйммәтен языгыз.

390. Икешәрле санау системасындагы 1110011 санын унарлы санау системасына күчерегез.

391. Рәсемдә А, Б, В, Г, Д, Е, Ж һәм К шәһәрләрен тоташтыра торган юллар схемасы бирелгән. Һәр юл буенча бары тик ук белән күрсәтелгән юнәлештә бер якка гына хәрәкәт итәргә мөмкин. А шәһәреннән К шәһәренә барлыгы ничә төрле юл белән барып була?



392. A, B, C, D, E торак пунктлары арасында юллар салынган, аларның озынлыгы (километрларда) түбәндәге таблицада бирелгән.

| | A | B | C | D | E |
|---|---|---|---|---|---|
| A | | 2 | 6 | 4 | |
| B | 2 | | 3 | | |
| C | 6 | 3 | | 3 | 2 |
| D | 4 | | 3 | | |
| E | | | 2 | | |

A һәм E пунктлары арасындагы иң кыска юлның озынлыгын табыгыз. Таблицада юл озынлыклары күрсәтелгән юллар буйлап кына хәрәкәтләнергә мөмкин.

1) 6

2) 7

3) 8

4) 9

393. Программада «:=» тамгасы – үзләштерү операторын, «+», «–», «*» и «/» тамгалары – бирелгән тәртиптә кушу, алу, тапкырлау һәм бүлү гамәлләрен аңлата. Операцияләр башкарылу кагыйдәләре һәм гамәлләр тәртибе арифметика кагыйдәләре белән туры килә.

Түбәндәге алгоритм башкарылганнан соң **а** үзгәрешлесенең кыйммәтен ачыклагыз:

a := 4

b := 4

b := a/2*b

a := 2*a+3*b

Җавапта бер бөтен сан – **а** үзгәрешлесенең кыйммәтен языгыз.

394. 64 Кбайт зурлыктагы файл секундына 1024 бит тизлек белән тапшырыла. Шуның кадәр үк вакыт сарыф итеп, секундына 256 бит тизлектәге башка тоташу аша нинди зурлыктагы файл (Кбайтларда) тапшырып булуын ачыклагыз.

Җавапта бер генә сан – Кбайтларда файл зурлыгын языгыз. Үлчәү берәмлеген язу кирәкми.

395. Бирелгән кайсы *X* кыйммәте өчен түбәндәге әйтем ЯЛГАН:

(*X* < 7) **ТҮГЕЛ ЯИСӘ** (*X* < 6)?

1) 4

2) 5

3) 6

4) 7

396. Сызым сызучы дип исемләнгән башкаручы координаталар яссылыгы буенча хәрәкәтләнә һәм артыннан сызык рәвешендә эз калдыра. Сызым сызучы **Күчәргә (*a*, *b*)** (a, b – бөтен саннар) командасын башкара ала, әлеге команда аны (*x*, *y*) координаталы ноктадан (*x + a*, *y + b*) координаталы ноктага күчерә. Әгәр *a*, *b* саннары уңай булсалар, координаталар тиңдәшле рәвештә арталар, тискәре булса – кимиләр.

*Мәсәлән, Сызым сызучы (4, 2) координаталы ноктада булса,* ***Күчәргә (2, –3)*** *командасы аны (6, –1) координаталы ноктага күчерәчәк.*

**Кабатла k тапкыр**

**Команда1 Команда2 Команда3**

**Ахыры**

язмасы **Команда1 Команда2 Команда3** командалары эзлеклегенең **k** тапкыр кабатлануын аңлата.

Сызым сызучыга башкару өчен түбәндәге алгоритм бирелгән:

**Кабатла 4 тапкыр**

**Команда1 Күчәргә (1, 3) Күчәргә (1, -2)**

**Ахыры**

**Күчәргә (-4, -12)**

Әлеге алгоритмны башкарганнан соң Сызым сызучы башлангыч ноктага әйләнеп катйкан. **Команда1** командасы урынына нинди команда куярга кирәк?

1) Күчәргә (2, 11)
2) Күчәргә (-1, 2)
3) Күчәргә (12, 4)
4) Күчәргә (1, -2)

397. Dat таблицасында халык җырларын башкаручы 10 кешегә бирелгән тавышлар саны турында мәгълүмат саклана (Dat[1] - беренче башкаручыга бирелгән тавышлар саны, Dat[2] – икенче башкаручыга һ.б.). Түбәндәге программа башкарылганнан соң нинди сан килеп чыгуын ачыклагыз. Программа тексты өч программалау телендә бирелгән .

| Алгоритм теле | Бейсик | Паскаль |
|---|---|---|
| алг<br>башы<br>бөтентаб Dat[1:10]<br>бөтен k, m<br>Dat[1] := 56<br>Dat[2] := 70<br>Dat[3] := 20<br>Dat[4] := 41<br>Dat[5] := 14<br>Dat[6] := 22 | DIM Dat(10) AS INTEGER<br>DIM k,m AS INTEGER<br>Dat(1) = 56: Dat(2) = 70<br>Dat(3) = 20: Dat(4) = 41<br>Dat(5) = 14: Dat(6) = 22<br>Dat(7) = 30: Dat(8) = 12<br>Dat(9) = 65:Dat(10) = 35<br>m = 0<br>FOR k = 1 TO 10<br>IF Dat(k)>m THEN | Var k, m: integer;<br>Dat: array[1..10] of integer;<br>Begin<br>Dat[1] := 56; Dat[2] := 70;<br>Dat[3] := 20; Dat[4] := 41;<br>Dat[5] := 14; Dat[6] := 22;<br>Dat[7] := 30; Dat[8] := 12;<br>Dat[9] := 65; Dat[10] := 35;<br>m := 0;<br>for k := 1 to 10 do |

| | | |
|---|---|---|
| Dat[7] := 30<br>Dat[8] := 12<br>Dat[9] := 65<br>Dat[10] := 35<br>m := 0<br><u>цб</u> k <u>өчен</u> 1 <u>дән</u> 10 <u>кадәр</u><br>  <u>әгәр</u> Dat[k]>m <u>ул вакытта</u><br>   m := Dat[k]<br>  <u>барлыгы</u><br><u>ца</u><br><u>чыгару</u> m<br><u>ахыры</u> | m = Dat(k)<br>ENDIF<br>NEXT k<br>PRINT m | if Dat[k]>m then<br>  begin<br>    m := Dat[k]<br>  end;<br>writeln(m);<br>End. |

398. Эзтабар штабка радиограмма тапшырган:

• – – • • • – • • – – • • – • – –

Әлеге радиограмма А, Д, Ж, Л, Т хәрефләре генә очраган хәрефләр эзлеклелеген эченә алган. Һәр хәреф Морзе әлифбасын кулланып кодланган. Хәреф кодлары арасында бүлгечләр юк. Җавапта тапшырылган хәрефләр эзлеклеген языгыз.

Морзе әлифбасының кирәкле фрагменты түбәндә китерелгән:

| А | Д | Ж | Л | Т |
|---|---|---|---|---|
| · _ | _ · · | · _ · · | _ | · · · _ |

399. Программада «:=» тамгасы – үзләштерү операторын, «+», «–», «*» и «/» тамгалары – бирелгән тәртиптә кушу, алу, тапкырлау һәм бүлү гамәлләрен аңлата. Операцияләр башкарылу кагыйдәләре һәм гамәлләр тәртибе арифметика кагыйдәләре белән туры килә.

Түбәндәге алгоритм башкарылганнан соң **а** үзгәрешлесенең кыйммәтен ачыклагыз:

```
a := 8
b := 2
b := a/2*b
a := 2*a+3*b
```

Җавапта бер бөтен сан – **а** үзгәрешлесенең кыйммәтен языгыз.

400. Бүлүче дип исемләнгән башкаручы ике команда башкара белә, алар номерланган:

**1. 2 санына бүл**

**2. 3 санын ал**

Беренче команда экрандагы санны 2 тапкырга, икенче команда – 3 санына киметә. Башкаручы бары тик натураль саннар белән генә эш йөртә.

**41 санын 4 санына** үзгәртә ала торган, 5 командадан артмаган алгоритм төзегез. Җавапта бары тик команда номерларын гына языгыз.

*(Мәсәлән, 11122 – 88 санын 5 санына үзгәртә торган алгоритм:*

*2 санына бүл*

*2 санына бүл*

*2 санына бүл*

*3 санын ал*

*3 санын ал)*

Андый алгоритмнар берничә булса, аларның берәрсен сайлап алып языгыз.

401. Малайлар шымчы (шпион) булып уйнаганнар һәм уйлап табылган шифр белән хәбәр кодлаганнар. Код таблицасы түбәндә бирелгән:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| К | Л | М | Н | О | П | Р |
| + – + | – * | * + | – + + | * | – – + | – – |

Алынган хәбәр шифрын чишегез:

*** + – + + – + + – – – ***

Җавапта шифры чишелгән хәбәрне языгыз.

402. 204 санын унарлы санау системасыннан икешәрле санау системасына күчерегез. Җавапта икешәрле санау системасындагы санны языгыз. Санау системасы нигезен язу кирәкми.

403. Сызым сызучы дип исемләнгән башкаручы координаталар яссылыгы буенча хәрәкәтләнә һәм артыннан сызык рәвешендә эз калдыра. Сызым сызучы **Күчәргә (*a, b*)** (a, b – бөтен саннар) командасын башкара ала, әлеге команда аны (*x, y*) координаталы ноктадан (*x + a, y + b*) координаталы ноктага күчерә. Әгәр *a*, *b* саннары уңай булсалар, координаталар тиңдәшле рәвештә арталар, тискәре булса – кимиләр.

*Мәсәлән, Сызым сызучы (9, 5) координаталы ноктада булса,* ***Күчәргә (1, –2)*** *командасы аны (10, 3) координаталы ноктага күчерәчәк.*

**Кабатла k тапкыр**

**Команда1 Команда2 Команда3**

**Ахыры**

язмасы **Команда1 Команда2 Команда3** командалары эзлеклегенең **k** тапкыр кабатлануын аңлата.

Сызым сызучыга башкару өчен түбәндәге алгоритм бирелгән:

**Кабатла 3 тапкыр**

**Күчәргә (-2, -3) Күчәргә (3, 2) Күчәргә (-4, 0)**

**Ахыры**

Әлеге алгоритмны алгоритм башкарылганнан соң Сызым сызучы шул ук ноктада булырдай нинди бер команда белән алыштырырга мөмкин?

1) Күчәргә (-9, -3)

2) Күчәргә (-3, 9)

3) Күчәргә (-3, -1)

4) Күчәргә (9, 3)

404. Төсле энҗе бөртекләре эзлеклелегенең кайсысы өчен әлеге әйтем хак:

(Икенче энҗе бөртеге сары) **ҺӘМ** (Дүртенче энҗе бөртеге яшел) **ТҮГЕЛ ҺӘМ** (Соңгы энҗе бөртеге кызыл) **ТҮГЕЛ**

(К – кызыл, С – сары, З – зәңгәр, Я – яшел)

1) ЗЯККСК

2) ССКЗЯК

3) ЗСЗЯКЯ

4) КСЯЗКЗ

405. Беренче хәбәрнең мәгълүмати күләме 1 Кбайт, ә икенчесенеке – 256 бит тәшкил итә. Әлеге ике хәбәрдә барлыгы ничә байт мәгълүмат бар? Җавапта бер сан языгыз.

406. 16 Кбайт зурлыктагы файлны билгеле бер тоташу аша тапшыруга 512 секунд вакыт сарыф ителгән. Әлеге тоташу аша 128 секундта тапшырылган файл зурлыгын (Кбайтларда) ачыклагыз.

Җавапта бер генә сан – Кбайтларда файл зурлыгын языгыз. Үлчәү берәмлеген язу кирәкми.

407. 1024 символдан торган хәбәрнең мәгълүмати күләме 1 Кбайт тәшкил итә. Әлеге хәбәрнең һәр символы никадәр бит белән кодлана?

1) 32

2) 16

3) 8

4) 4

408. Кулланучы һәр символы 16 бит белән кодлана торган Unicode кодировкасында 256 символдан торган хәбәр язган. Редакцияләгәннән соң хәбәрнең мәгълүмати күләме 3072 бит булып калган. Кодировка үзгәртелмәгәнен истә тотып, хәбәрдән ничә символ бетерелүен ачыклагыз.

1) 100

2) 64

3) 32

4) 16

409. Билгеле бер алгоритм бирелгән символлар чылбырыннан әлеге ысулны кулланып яңа чылбыр төзи. Символлар чылбыры хәрефтән башланса, чылбырның башына һәм ахырына **9** өстәлә. Башка очракта чылбырның беренче символы бетерелә. Килеп чыккан яңа символлар

чылбырында һәр хәреф рус алфавитындагы аннан алда килгән хәреф белән алыштырыла (**Б** – **А** хәрефенә, **В** – **Б** хәрефенә, ..., **А** – **Я** хәрефенә).

Килеп чыккан яңа чылбыр әлеге алгоритм эше нәтиҗәсе булып тора.

Мәсәлән, башлангыч символлар чылбыры **Т5** булса, алгоритм эше нәтиҗәсе – **9С59**, ә башлангыч символлар чылбыры **5Г3** булса, ул вакытта алгоритм эше нәтиҗәсе – **В3** чылбыры булачак.

**Д1М6У** символлар чылбыры бирелгән. Әлеге символлар чылбырына карата алгоритмны ике тапкыр куллансак, нәтиҗәдә нинди символлар чылбыры килеп чыгачак (ягъни бирелгән символлар чылбырына карата алгоритм кулланып, килеп чыккан нәтиҗәгә карата тагын әлеге алгоритмны куллансак)?

Рус алфавиты: **АБВГДЕЁЖЗИЙКЛМНОПРСТУФХЦЧШЩЪЫЬЭЮЯ**

410. Кырмыска исемле башкаручы шакмакларга бүленгән кыр буенча хәрәкәтләнә. Кырның үлчәмнәре – 8x8, юллар саннар белән, ә баганалар хәрефләр белән тамгалана.

Кырмыска хәрәкәтләнү командаларын башкара ала:

**өскә N,**

**аска N,**

**уңга N,**

**сулга N,** (монда *N* – 1 дән 7 гә кадәр бөтен сан), алар бирелгән тәртиптә башкаручыны N шакмак өскә, аска, уңга яисә сулга күчерәләр.

**кабатла *k* тапкыр**

**команда1 команда2 команда3**

**ца**

- **команда1 команда2 команда3** командалар эзлеклегенең ***k*** тапкыр кабатлануын аңлата.

Юлында куб очраса, Кырмыска аны этеп куя. Мәсәлән, куб **Д4** шакмагында тора ди.

Әгәр Кырмыска **өскә 3 уңга 2** командаларын башкарса, ул **Ж5** шакмагында, ә куб **Д6** шакмагында булачак.

Кырмыска һәм куб рәсемдә сурәтләнгәнчә урнашкан булсыннар, ди.



Кырмыскага түбәндәге алгоритм бирелгән:

**кабатла *2* тапкыр**

**уңга 1 өскә 2 сулга 3 аска 1**

**ца**

Әлеге алгоритмны башкарганнан соң куб кайсы шакмакта булачак?

1) А4

2) Б4

3) Б7

4) Д4

411. Программада «:=» тамгасы – үзләштерү операторын, «+», «–», «*» и «/» тамгалары – бирелгән тәртиптә кушу, алу, тапкырлау һәм бүлү гамәлләрен аңлата. Операцияләр башкарылу кагыйдәләре һәм гамәлләр тәртибе арифметика кагыйдәләре белән туры килә.

Түбәндәге алгоритм башкарылганнан соң **a** үзгәрешлесенең кыйммәтен ачыклагыз:

a := 36

b := a/12

b := b+a/4

a := a/b*3

Җавапта бер сан – **a** үзгәрешлесенең кыйммәтен языгыз.

412. 8 Кбайт зурлыктагы файл секундына 4096 бит тизлек белән тапшырыла. Шуның кадәр үк вакыт сарыф итеп секундына 256 бит тизлектәге башка тоташу аша нинди зурлыктагы файл (байтларда) тапшырып булуын ачыклагыз.

Җавапта бер генә сан – байтларда файл зурлыгын языгыз. Үлчәү берәмлеген язу кирәкми.

413. Программада «:=» тамгасы – үзләштерү операторын, «+», «–», «*» и «/» тамгалары – бирелгән тәртиптә кушу, алу, тапкырлау һәм бүлү гамәлләрен аңлата. Операцияләр башкарылу кагыйдәләре һәм гамәлләр тәртибе арифметика кагыйдәләре белән туры килә.

Түбәндәге алгоритм башкарылганнан соң **b** үзгәрешлесенең кыйммәтен ачыклагыз:

a := 81

b := a/3

a := b+2*a

b := a/9*3

Җавапта бер сан – **b** үзгәрешлесенең кыйммәтен языгыз.

414. Бер сан икешәрле санау системасында 11010010 буларак языла. Әлеге санны унарлы санау системасында языгыз.

415. $2^{23}$ байт күләмле хәбәрдә ничә Мбайт мәгълүмат бар?

416. Кырмыска исемле башкаручы шакмакларга бүленгән кыр буенча хәрәкәтләнә. Кырның үлчәмнәре – 8х8, юллар саннар белән, ә баганалар хәрефләр белән тамгалана.

Кырмыска хәрәкәтләнү командаларын башкара ала:

**өскә N,**

**аска N,**

**уңга N,**

**сулга N,** (монда *N* – 1 дән 7 гә кадәр бөтен сан), алар бирелгән тәртиптә башкаручыны N шакмак өскә, аска, уңга яисә сулга күчерәләр.

**кабатла *k* тапкыр**

**команда1 команда2 команда3**

**ца**

- **команда1 команда2 команда3** командалар эзлеклегенең ***k*** тапкыр кабатлануын аңлата.

Юлында куб очраса, Кырмыска аны этеп куя. Мәсәлән, куб **Г6** шакмагында тора ди.

Әгәр Кырмыска **аска 1 уңга 3 сулга 2** командаларын башкарса, ул **В6** шакмагында, ә куб **Е6** шакмагында булачак.

Кырмыска һәм куб рәсемдә сурәтләнгәнчә урнашкан булсыннар, ди.




Кырмыскага түбәндәге алгоритм бирелгән:

**кабатла *3* тапкыр**

**уңга 2 аска 3 сулга 2 өскә 2**

**ца**

Әлеге алгоритмны башкарганнан соң куб кайсы шакмакта булачак?

1) Б1

2) Б4

3) Г1

4) Г6

417. A, B, C, D, E торак пунктлары арасында юллар салынган, аларның озынлыгы (километрларда) түбәндәге таблицада бирелгән.

| | A | B | C | D | E |
|---|---|---|---|---|---|
| A | | 2 | 4 | | 6 |
| B | 2 | | 1 | | |
| C | 4 | 1 | | 5 | 1 |
| D | | | 5 | | 3 |
| E | 6 | | 1 | 3 | |

A һәм D пунктлары арасындагы иң кыска юлның озынлыгын табыгыз. Таблицада юл озынлыклары күрсәтелгән юллар буйлап кына хәрәкәтләнергә мөмкин.

1) 6

2) 7

3) 8

4) 9

418. Билгеле бер алгоритм бирелгән символлар чылбырыннан әлеге ысулны кулланып, яңа чылбыр төзи. Иң элек бирелгән символлар чылбырының озынлыгы исәпләп чыгарыла; ул так булган очракта чылбырның уртадагы символы икегә тапкырлана, ә җөп булса, чылбыр алдына **1** символы өстәлә. Килеп чыккан юлда һәр цифр аннан соң килгән цифр белән алыштырыла (**1** – **2** цифрына, **2** – **3** кә, ..., **9** – **0** цифрына).

Килеп чыккан яңа чылбыр әлеге алгоритм эше нәтиҗәсе булып тора.

Мәсәлән, башлангыч символлар чылбыры **356** булса, алгоритм эше нәтиҗәсе – **4667** символлар чылбыры булачак, ә башлангыч символлар чылбыры **52** булса, ул вакытта алгоритм эше нәтиҗәсе – **263** булачак.

**35842** символлар чылбыры бирелгән. Әлеге символлар чылбырына карата алгоритмны ике тапкыр куллансак, нәтиҗәдә нинди символлар чылбыры килеп чыгачак (ягъни бирелгән символлар чылбырына карата алгоритм кулланып, килеп чыккан нәтиҗәгә карата тагын әлеге алгоритмны куллансак)?

419. Программада «:=» тамгасы – үзләштерү операторын, «+», «–», «*» и «/» тамгалары – бирелгән тәртиптә кушу, алу, тапкырлау һәм бүлү гамәлләрен аңлата. Операцияләр башкарылу кагыйдәләре һәм гамәлләр тәртибе арифметика кагыйдәләре белән туры килә.

Түбәндәге алгоритм башкарылганнан соң **a** үзгәрешлесенең кыйммәтен ачыклагыз:

a := 5

b := a*4+4

b := b/(a-1)

a := a*b/2*3

Җавапта бер сан – **a** үзгәрешлесенең кыйммәтен языгыз.

420. Эзтабардан түбәндәге шифрланган радиограмма килгән, ул Морзе әлифбасын кулланып тапшырылган:

• — • — — • — — • • — • • — — •

Радиограмма тапшырганда хәрефләргә бүленеш югалган, шулай да, радиограммада түбәндәге хәрефләр генә кулланылган булуы мәгълүм :

| А | Г | И | П | М |
|---|---|---|---|---|
| · _ | _ _ · | · · | · _ _ · | _ _ |

Радиограмма текстын ачыклагыз. Җавапта радиограммада булган хәрефләр санын языгыз.

421. Хисаплаучы дип исемләнгән башкаручы ике команда башкара белә, алар номерланган:

**1. 1 санын өстәп яз**

**2. 3 санына бүл**

Беренче команда экрандагы санның уң ягына 1 санын өстәп яза, икенче команда – санны өч тапкырга киметә.

**5 санын 19 санына** үзгәртә ала торган, 5 командадан артмаган алгоритм төзегез. Җавапта бары тик команда номерларын гына языгыз.

*(Мәсәлән, 22121 – 18 санын 71 санына үзгәртә торган алгоритм:*

*3 санына бүл*

*3 санына бүл*

*1 санын өстәп яз*

*3 санына бүл*

*1 санын өстәп яз)*

Андый алгоритмнар берничә булса, аларның берәрсен сайлап алып языгыз.

422. 375 Кбайт зурлыктагы файлны билгеле бер тоташу аша тапшыруга 24 секунд вакыт сарыф ителгән. Әлеге тоташу аша бит/секундларда тапшыру тизлеген исәпләп чыгарыгыз.

Җавапта бер генә сан языгыз. Үлчәү берәмлеген язу кирәкми.

423. Беренче файлның мәгълүмати күләме 2 Кбайт, ә икенчесенеке – 101 байт тәшкил итә. Әлеге ике файлның байтларда гомуми күләме күпме?

Җавапта бер сан языгыз.

424. Эзтабардан түбәндәге шифрланган радиограмма килгән, ул Морзе әлифбасын кулланып тапшырылган:

• _ _ • • • _ • • _ _ • • _ • _ _

Радиограмма тапшырганда хәрефләргә бүленеш югалган, шулай да, радиограммада түбәндәге хәрефләр генә кулланылган булуы мәгълүм :

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| А | Д | Л | Т | Ж |
| · _ | _ · · | · _ · · | _ | · · · _ |

Радиограмма текстын ачыклагыз. Җавапта радиограммада булган хәрефләр санын языгыз.

425. Хисаплаучы дип исемләнгән башкаручы ике команда башкара белә, алар номерланган:

**1. 4 санын ал**

**2. 2 санын өстәп яз**

Беренче команда экрандагы санны 4 санына киметә, икенче команда – санның уң ягына 2 санын өстәп яза.

**9 санын 4 санына** үзгәртә ала торган, 5 командадан артмаган алгоритм төзегез. Җавапта бары тик команда номерларын гына языгыз.

*(Мәсәлән, 12111 – 6 санын 10 санына үзгәртә торган алгоритм:*

*4 санын ал*

*2 санын өстәп яз*

*4 санын ал*

*4 санын ал*

*4 санын ал)*

Андый алгоритмнар берничә булса, аларның берәрсен сайлап алып языгыз.

426. Бирелгән кайсы *X* кыйммәте өчен түбәндәге аңлатма ЯЛГАН:

(*X* > 2) **ТҮГЕЛ ЯИСӘ** ((*X* < 4) **ҺӘМ** (X > 1))?

1) 1

2) 2

3) 3

4) 4

427. Квадратор дип исемләнгән башкаручы ике команда башкара белә, алар номерланган:

**1. квадратка күтәр**

**2. уңнан сызып ташла**

Беренче команда экрандагы санны 2 нче дәрәҗәгә күтәрә, икенче команда – иң уң яктагы цифрны бетерә.

**3 санын 6 санына** үзгәртә ала торган, 5 командадан артмаган алгоритм төзегез. Җавапта бары тик команда номерларын гына языгыз.

*(Мәсәлән, 21211 – 52 санын 16 санына үзгәртә торган алгоритм:*

*уңнан сызып ташла*

*квадратка күтәр*

*уңнан сызып ташла*

*квадратка күтәр*

*квадратка күтәр)*

Андый алгоритмнар берничә булса, аларның берәрсен сайлап алып языгыз.

428. Квадратор дип исемләнгән башкаручы ике команда башкара белә, алар номерланган:

**1. квадратка күтәр**

**2. 5 санын ал**

Беренче команда экрандагы санны 2 нче дәрәҗәгә күтәрә, икенче команда – 5 санына киметә.

**3 санын 6 санына** үзгәртә ала торган, 5 командадан артмаган алгоритм төзегез. Җавапта бары тик команда номерларын гына языгыз.

*(Мәсәлән, 21221 – 10 санын 225 санына үзгәртә торган алгоритм:*

*5 санын ал*

*квадратка күтәр*

*5 санын ал*

*5 санын ал*

*квадратка күтәр)*

Андый алгоритмнар берничә булса, аларның берәрсен сайлап алып языгыз.

429. Программада «:=» тамгасы – үзләштерү операторын, «+», «–», «*» и «/» тамгалары – бирелгән тәртиптә кушу, алу, тапкырлау һәм бүлү гамәлләрен аңлата. Операцияләр башкарылу кагыйдәләре һәм гамәлләр тәртибе арифметика кагыйдәләре белән туры килә.

Түбәндәге алгоритм башкарылганнан соң **a** үзгәрешлесенең кыйммәтен ачыклагыз:

```
b := -1
a := 15+b*3
b := a*b/2
a := a/b*4+10
```

Җавапта бер сан – **a** үзгәрешлесенең кыйммәтен языгыз.

430. Беренче хәбәрнең мәгълүмати күләме 0,25 Кбайт тәшкил итә, ә икенчесенеке – 512 бит. Икенче хәбәрнең мәгълүмати күләме беренчесенекенә караганда ничә тапкыр ким?

431. Хисаплаучы дип исемләнгән башкаручы ике команда башкара белә, алар номерланган:

**1. 4 санын өстәп яз**

**2. 2 санына бүл**

Беренче команда экрандагы санның уң ягына 4 санын өстәп яза, икенче команда – санны 2 тапкыр киметә.

**8 санын 7 санына** үзгәртә ала торган, 5 командадан артмаган алгоритм төзегез. Җавапта бары тик команда номерларын гына языгыз.

*(Мәсәлән, 12212 – 2 санын 32 санына үзгәртә торган алгоритм:*

*4 санын өстәп яз*

*2 санына бүл*

*2 санына бүл*

*4 санын өстәп яз*

*2 санына бүл)*

Андый алгоритмнар берничә булса, аларның берәрсен сайлап алып языгыз.

432. ADSL-тоташу аша мәгълүмат тапшыру тизлеге – $2^{13}$ бит/с.

Әлеге тоташу аша файл тапшыру 2 минут вакыт алды. Файл күләмен (Кбайтларда) ачыклагыз.

Җавапта бер генә сан – Кбайтларда файл зурлыгын языгыз. Үлчәү берәмлеген язу кирәкми.

433. 201 санын унарлы санау системасыннан икешәрле санау системасына күчерегез. Җавапта икешәрле санау системасындагы санны языгыз. Санау системасы нигезен язу кирәкми.

434. Хисаплаучы дип исемләнгән башкаручы ике команда башкара белә, алар номерланган:

**1. 1 санын ал**

**2. квадратка күтәр**

Беренче команда экрандагы санны 1 санына киметә, икенче команда – 2 нче дәрәҗәгә күтәрә.

**3 санын 62 санына** үзгәртә ала торган, 5 командадан артмаган алгоритм төзегез. Җавапта бары тик команда номерларын гына языгыз.

*(Мәсәлән, 12112 – 4 санын 49 санына үзгәртә торган алгоритм:*

*1 санын ал*

*квадратка күтәр*

*1 санын ал*

*1 санын ал*

*квадратка күтәр)*

Андый алгоритмнар берничә булса, аларның берәрсен сайлап алып языгыз.

435. ADSL-тоташу аша мәгълүмат тапшыру тизлеге – 512000 бит/с.

Әлеге тоташу аша файл тапшыру 8 секунд вакыт алды. Файл күләмен (Кбайтларда) ачыклагыз.

Җавапта бер генә сан – Кбайтларда файл зурлыгын языгыз. Үлчәү берәмлеген язу кирәкми.

436. Хәбәр код белән шифрланган. Бары тик таблицада булган хәрефләр генә кулланылган:

| А | Б | В | Г | Д | Е |
|---|---|---|---|---|---|
| . . o . . | . o . . o | . oo . o | . oooo | . . . o . | . o . oo |

Хәбәрдә кайсы хәрефләр кабатланганын ачыклагыз һәм җавапта языгыз.

. . . o . . o . oo . . . o . . oooo . o . oo

437. $2^{30}$ бит күләмле хәбәрдә ничә Мбайт мәгълүмат бар?

Җавапта бер сан гына языгыз.

438. ADSL-тоташу аша мәгълүмат тапшыру тизлеге – 128000 бит/с.

Әлеге тоташу аша файл тапшыру 32 секунд вакыт алды. Файл күләмен (Кбайтларда) ачыклагыз.

Җавапта бер генә сан – Кбайтларда файл зурлыгын языгыз. Үлчәү берәмлеген язу кирәкми.

439. Таблицада биш шәһәр - A, B, C, D һәм E арасында юлларның булу-булмавы чагылдырылган. Юл һәм багана киселешендә 1 саны шәһәрләр арасында юлның барлыгын аңлата. Таблицага туры килгән схеманы табыгыз.

| | A | B | C | D | E |
|---|---|---|---|---|---|
| A | | 0 | 0 | 0 | 1 |
| B | 0 | | 1 | 1 | 1 |
| C | 0 | 1 | | 1 | 0 |
| D | 0 | 1 | 1 | | 0 |
| E | 1 | 1 | 0 | 0 | |




1)




2)




3)




4)

440. Таблицада биш шәһәр - A, B, C, D һәм E арасында юлларның булу-булмавы чагылдырылган. Юл һәм багана киселешендә 1 саны шәһәрләр арасында юлның барлыгын аңлата. Таблицага туры килгән схеманы табыгыз.

| | A | B | C | D | E |
|---|---|---|---|---|---|
| A | | 0 | 1 | 1 | 0 |
| B | 0 | | 1 | 0 | 1 |
| C | 1 | 1 | | 1 | 0 |
| D | 1 | 0 | 1 | | 0 |
| E | 0 | 1 | 0 | 0 | |



1)



2)



3)



4)

441. Бер сан икешәрле санау системасында 1100101 буларак языла. Әлеге санны унарлы санау системасында языгыз.

442. Мәгълүмати күләме 0,5 Кбайт булган хәбәр 256 символдан тора. Әлеге хәбәрнең һәр символы никадәр бит белән кодлана?

1) 32

2) 16

3) 8

4) 4

443. Компьютерда җыелган мәкалә 64 биттән тора, һәр биттә 40 юл, һәр юлда 56 символ бар. Һәр символ 16 бит белән кодлана торган Unicode кодировкаларының берсендә әлеге мәкаләнең мәгълүмати күләмен ачыклагыз.

1) 2240 байт

2) 280 Кбайт

3) 1120 байт

4) 140 Кбайт

444. $2^{17}$ бит күләмле хәбәрдә ничә Кбайт мәгълүмат бар?

Җавапта бер сан гына языгыз.

445. WAP-тоташу аша мәгълүмат тапшыру тизлеге – 512000 бит/с.

Әлеге тоташу аша 500 Кбайт тапшырылган. Файлны тапшыру өчен ничә секунд вакыт кирәк булган?

Җавапта бер генә сан – секундларда тапшыру дәвамлылыгын языгыз. Үлчәү берәмлеген язу кирәкми.

446. Төсле энҗе бөртекләре эзлеклелегенең кайсысы өчен әлеге әйтем хак:

(Соңгы энҗе бөртеге яшел) **ЯИСӘ** ((Икенче энҗе бөртеге кызыл) **ҺӘМ** (Дүртенче энҗе бөртеге яшел))

(К – кызыл, С – сары, З – зәңгәр, Я – яшел)

1) ЯКЯЗС

2) КЗЯСК

3) ККЗЯК

4) ЯЯКЯЗ

447. Әлеге исемнәрнең кайсысы өчен түбәндәге әйтем хак:

(Беренче хәреф сузык) **ТҮГЕЛ ҺӘМ** (Соңгы хәреф тартык) **ТҮГЕЛ**?

1) Әхмәди

2) Ирек

3) Камил

4) Шәвәли

448. ADSL-тоташу аша мәгълүмат тапшыру тизлеге – 256000 бит/с.

Файл күләме 500 Кбайт булса, әлеге тоташу аша бу файлны тапшыру өчен, ничә секунд вакыт кирәк булачак?

Җавапта бер генә сан – секундларда тапшыру дәвамлылыгын языгыз. Үлчәү берәмлеген язу кирәкми.

449. 2048 символдан торган хәбәрнең мәгълүмати күләме 2 Кбайт тәшкил итә. Әлеге хәбәрнең һәр символы никадәр бит белән кодлана?

1) 32

2) 16

3) 8

4) 4

450. Программада «:=» тамгасы – үзләштерү операторын, «+», «–», «*» и «/» тамгалары – бирелгән тәртиптә кушу, алу, тапкырлау һәм бүлү гамәлләрен аңлата. Операцияләр башкарылу кагыйдәләре һәм гамәлләр тәртибе арифметика кагыйдәләре белән туры килә.

Түбәндәге алгоритм башкарылганнан соң **а** үзгәрешлесенең кыйммәтен ачыклагыз:

a := 6

b := a/3+1

b := a/b*2

a := b*2-a

Җавапта бер сан – **а** үзгәрешлесенең кыйммәтен языгыз.

451. КОИ-8 кодировкасында һәр символ 1 байт белән кодлана. Әлеге кодировкада түбәндә бирелгән җөмләнең мәгълүмати күләмен исәпләп чыгарыгыз:

**Каков вопрос, таков и ответ.**

**1)** 224 байт

**2)** 192 бит

**3)** 224 бит

**4)** 200 бит

452. Беренче хәбәрнең мәгълүмати күләме 1,5 Кбайт тәшкил итә, ә икенчесенеке – 128 бит. Әлеге ике хәбәрнең байтларда гомуми күләме күпме?

Җавапта бер сан языгыз.

453. WAP-тоташу аша мәгълүмат тапшыру тизлеге – 512000 бит/с. Әлеге тоташу аша файл тапшыру 10 секунд вакыт алган. Файл күләмен (Кбайтларда) ачыклагыз. Җавапта бер генә сан языгыз. Үлчәү берәмлеген язу кирәкми.

454. Хәбәр код белән шифрланган. Бары тик таблицада булган хәрефләр генә кулланылган :

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| А | Б | В | Г | Д | Е |
| ..o.. | .o..o | .oo.o | .oooo | ...o. | .o.oo |

Хәбәрдә кайсы хәрефләр кабатланганын ачыклагыз һәм җавапта языгыз.

.o..o.o.oo.o..o..o....o..

455. Кырмыска исемле башкаручы шакмакларга бүленгән кыр буенча хәрәкәтләнә. Кырның үлчәмнәре – 8х8, юллар саннар белән, ә баганалар хәрефләр белән тамгалана.

Кырмыска хәрәкәтләнү командаларын башкара ала:

**өскә N,**

**аска N,**

**уңга N,**

**сулга N,** (монда *N* – 1 дән 7 гә кадәр бөтен сан), алар бирелгән тәртиптә башкаручыны N шакмак өскә, аска, уңга яисә сулга күчерәләр.

**кабатла *k* тапкыр**

**команда1 команда2 команда3**

**ца**

- **команда1 команда2 команда3** командалар эзлеклегенең ***k*** тапкыр кабатлануын аңлата.

Юлында куб очраса, Кырмыска аны этеп куя. Мәсәлән, куб **В5** шакмагында тора ди.

Әгәр Кырмыска **уңга 1 өскә 3 уңга 2** командаларын башкарса, ул **Д5** шакмагында, ә куб **В6** шакмагында булачак.

Кырмыска һәм куб рәсемдә сурәтләнгәнчә урнашкан булсыннар, ди.




Кырмыскага түбәндәге алгоритм бирелгән:

**кабатла *3* тапкыр**

**сулга 1 өскә 3 уңга 2 аска 3**

**ца**

Әлеге алгоритмны башкарганнан соң куб кайсы шакмакта булачак?

1) В5
2) Д2
3) Д5
4) Е5

456. Малайлар шымчы (шпион) булып уйнаганнар һәм уйлап табылган шифр белән хәбәр кодлаганнар. Код таблицасы түбәндә бирелгән :

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| А | Б | В | Г | Е | И | К |
| * | – + + | – – + | * + | – * | + – + | * * – |

Алынган хәбәр шифрын чишегез:

*** + – + + – * * – * ***

457. A, B, C, D торак пунктлары арасында юллар салынган, аларның озынлыгы (километрларда) түбәндәге таблицада бирелгән.

| | A | B | C | D |
|---|---|---|---|---|
| A | | 5 | 8 | 3 |
| B | 5 | | 2 | 1 |
| C | 8 | 2 | | 4 |
| D | 3 | 1 | 4 | |

А һәм С пунктлары арасындагы иң кыска юлның озынлыгын табыгыз. Таблицада юл озынлыклары күрсәтелгән юллар буйлап кына хәрәкәтләнергә мөмкин.

1) 5
2) 6
3) 7
4) 8

458. Ташбака дип исемләнгән башкаручы компьютер экраны буйлап хәрәкәтләнә һәм артыннан сызык рәвешендә эз калдыра. Һәр конкрет вакыт аралыгында башкаручының торган урыны һәм хәрәкәтләнү юнәлеше билгеле. Башкаручы ике команда башкара ала:

**Алга n** (n – бөтен сан), Ташбаканы хәрәкәтләнү юнәлешендә n адымга атлата; **Уңга m** (m – бөтен сан), Ташбаканың хәрәкәтләнү юнәлешен сәгать теле уңаена (уңга) m градуска бора.

**Кабатла k [Команда1 Команда2 Команда3]** язмасы җәя эчендәге командалар эзлеклегенең **k** тапкыр кабатлануын аңлата.

*Ташбакага башкару өчен төзек алтыпочмак сурәтен ясау алгоритмы бирелгән:*

**Кабатла 3 [Уңга 60 Алга 50 *** Алга 50]**

Йолдызчыклар (***) урынында алгоритмда нинди команда булырга тиеш?

1) Алга 30
2) Алга 60
3) Уңга 30
4) Уңга 60

459. Беренче файлның мәгълүмати күләме 65 байт, ә икенчесенеке – 880 бит тәшкил итә. Әлеге ике файлның байтларда гомуми күләме күпме?

Җавапта бер сан языгыз.

460. Квадратор дип исемләнгән башкаручы ике команда башкара белә, алар номерланган:

**1. сулдан сызып ташла**

**2. квадратка күтәр**

Беренче команда экрандагы санның иң сул яктагы цифрын бетерә, икенче команда – санны 2 нче дәрәҗәгә күтәрә.

**8 санын 56 санына** үзгәртә ала торган, 5 командадан артмаган алгоритм төзегез. Җавапта бары тик команда номерларын гына языгыз.

*(Мәсәлән, 12212 – 12 санын 36 санына үзгәртә торган алгоритм:*

*сулдан сызып ташла*

*квадратка күтәр*

*квадратка күтәр*

*сулдан сызып ташла*

*квадратка күтәр)*

Андый алгоритмнар берничә булса, аларның берәрсен сайлап алып языгыз.

461. Бирелгән кайсы *X* кыйммәте өчен түбәндәге аңлатма ЯЛГАН:

($X > 3$) **ЯИСӘ** (($X < 4$) **ҺӘМ** ($X > 2$)) **ТҮГЕЛ**?

1) 1
2) 2
3) 3
4) 4

462. КОИ-8 кодировкасында һәр символ 1 байт белән кодлана. Әлеге кодировкада түбәндә бирелгән җөмләнең мәгълүмати күләмен исәпләп чыгарыгыз:

**Вода и землю, и камень точит.**

1) 184 бит

2) 232 бит

3) 24 байт

4) 216 байт

463. $2^{12}$ бит күләмле хәбәрдә ничә байт мәгълүмат бар?

Җавапта бер сан гына языгыз.

464. Бирелгән кайсы *X* кыйммәте өчен түбәндәге аңлатма ЯЛГАН:

((*X* ≥ 6) **ТҮГЕЛ ҺӘМ** (*X* = 5) **ТҮГЕЛ**) **ЯИСӘ** (X ≤ 7)?

1) 5
2) 6
3) 7
4) 8

465. Бер сан икешәрле санау системасында 11001110 буларак языла. Әлеге санны унарлы санау системасында языгыз.

466. Әлеге исемнәрнең кайсысы өчен түбәндәге әйтем хак:

(Беренче хәреф тартык) **ҺӘМ** (Соңгы хәреф сузык) **ТҮГЕЛ ҺӘМ** (бишенче хәреф сузык)?

1) Ирек

2) Зөлфәт

3) Самат

4) Фәнәви

467. ADSL-тоташу аша мәгълүмат тапшыру тизлеге – 128000 бит/с.

Файл күләме 250 Кбайт булса, әлеге тоташу аша бу файлны тапшыру өчен ничә секунд вакыт кирәк булачак?

Җавапта бер генә сан – секундларда тапшыру дәвамлылыгын языгыз. Үлчәү берәмлеген язу кирәкми.

468. Хәбәр код белән шифрланган. Бары тик таблицада булган хәрефләр генә кулланылган :

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| А | Б | В | Г | Д | Е |
| . . о . . | . о . . о | . оо . о | . оооо | . . . о . | . о . оо |

Хәбәрдә кайсы хәрефләр кабатланганын ачыклагыз һәм җавапта языгыз.

.о..о.оо.о.оо.о...о..о.оо

469. Ташбака дип исемләнгән башкаручы компьютер экраны буйлап хәрәкәтләнә һәм артыннан сызык рәвешендә эз калдыра. Һәр конкрет вакыт аралыгында башкаручының торган урыны һәм хәрәкәтләнү юнәлеше билгеле. Башкаручы ике команда башкара ала:

**Алга n** (n – бөтен сан), Ташбаканы хәрәкәтләнү юнәлешендә n адымга атлата; **Уңга m** (m – бөтен сан), Ташбаканың хәрәкәтләнү юнәлешен сәгать теле уңаена (уңга) m градуска бора.

**Кабатла k [Команда1 Команда2 Команда3]** язмасы җәя эчендәге командалар эзлеклегенең **k** тапкыр кабатлануын аңлата.

*Ташбакага башкару өчен түбәндәге алгоритм бирелгән:*

**Кабатла 8 [Алга 50 Уңга 60 Уңга 30]**

Экранда нинди фигура барлыкка киләчәк?

1) квадрат
2) төзек сигезпочмак
3) төзек уналтыпочмак
4) йомык булмаган сынык сызык

470. Бер сан икешәрле санау системасында 1100110 буларак языла. Әлеге санны унарлы санау системасында языгыз.

471. Малайлар шымчы (шпион) булып уйнаганнар һәм уйлап табылган шифр белән хәбәр кодлаганнар. Хәбәрдә бары тик бирелгән код таблицасы фрагментындагы хәрефләр генә бар :

| С | Т | У | Ф | Х | Ц | Ч |
|---|---|---|---|---|---|---|
| – | + + * | + – | + * + | * * | – * | + * * |

Килгән хәбәрдә ничә хәреф булганын ачыклагыз:

**– * * * + + * + + * + –**

472. Эзтабардан түбәндәге шифрланган радиограмма килгән, ул Морзе әлифбасын кулланып тапшырылган:

_ _ • _ _ _ _ _ • • • _ _ _ • _ • _

Радиограмма тапшырганда хәрефләргә бүленеш югалган, шулай да, радиограммада түбәндәге хәрефләр генә кулланылган булуы мәгълүм:

| А | Г | М | К | Ю |
|---|---|---|---|---|
| · _ | _ _ · | _ _ | _ · _ | · · _ _ |

Радиограмма текстын ачыклагыз. Җавапта радиограммада булган хәрефләр санын языгыз.

473. 3750 Кбайт зурлыктагы файлны билгеле бер тоташу аша тапшыруга 2 минут вакыт сарыф ителгән. Әлеге тоташу аша бит/секундларда тапшыру тизлеген исәпләп чыгарыгыз.

Җавапта бер генә сан языгыз. Үлчәү берәмлеген язу кирәкми.

474. Программада «:=» тамгасы – үзләштерү операторын, «+», «–», «*» и «/» тамгалары – бирелгән тәртиптә кушу, алу, тапкырлау һәм бүлү гамәлләрен аңлата. Операцияләр башкарылу кагыйдәләре һәм гамәлләр тәртибе арифметика кагыйдәләре белән туры килә.

Түбәндәге алгоритм башкарылганнан соң **а** үзгәрешлесенең кыйммәтен ачыклагыз:

a := 8

b := a-3

b := 2*b+4

a := b/7-1

Җавапта бер сан – **а** үзгәрешлесенең кыйммәтен языгыз.

475. Камил һәм Шамил шымчы (шпион) булып уйнаганнар һәм хәбәрләрен үз шифрлары белән шифрлаганнар. Әлеге код таблицасының бер фрагменты түбәндә бирелгән:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| А | Б | В | Г | Д | Е |
| ~ | # | # + | + ~ # | + # | ~ # |

Хәрефләр кабатланмавы билгеле, моны истә тотып хәбәрнең ничә хәрефтән торганын ачыклагыз:

**# ~ # ~ # + + ~ #**

476. Ташбака дип исемләнгән башкаручы компьютер экраны буйлап хәрәкәтләнә һәм артыннан сызык рәвешендә эз калдыра. Һәр конкрет вакыт аралыгында башкаручының торган урыны һәм хәрәкәтләнү юнәлеше билгеле. Башкаручы ике команда башкара ала:

**Алга n** (n – бөтен сан), Ташбаканы хәрәкәтләнү юнәлешендә n адымга атлата; **Уңга m** (m – бөтен сан), Ташбаканың хәрәкәтләнү юнәлешен сәгать теле уңаена (уңга) m градуска бора.

**Кабатла k [Команда1 Команда2 Команда3]** язмасы җәя эчендәге командалар эзлеклегенең **k** тапкыр кабатлануын аңлата.

*Ташбакага башкару өчен түбәндәге алгоритм бирелгән:*

**Кабатла 5 [Алга 50 Уңга 10 Уңга 50]**

Экранда нинди фигура барлыкка киләчәк?

1) төзек бишпочмак

2) төзек алтыпочмак

3) төзек уникепочмак

4) йомык булмаган сынык сызык

477. Камил һәм Шамил шымчы (шпион) булып уйнаганнар һәм хәбәрләрен үз шифрлары белән шифрлаганнар. Әлеге код таблицасының бер фрагменты түбәндә бирелгән:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| К | Л | М | Н | О | П |
| **@** + | ~ + | + **@** | **@** ~ + | + | ~ |

Хәрефләр кабатланмавы билгеле, моны истә тотып хәбәрнең ничә хәрефтән торганын ачыклагыз:

**+ ~ + ~ + @ @ ~ +**

478. Төсле энҗе бөртекләре эзлеклелегенең кайсысы өчен әлеге әйтем хак:

((Беренче энҗе бөртеге кызыл) **ТҮГЕЛ ҺӘМ** (Өченче энҗе бөртеге зәңгәр)) **ЯИСӘ** (Бишенче энҗе бөртеге яшел))

(К – кызыл, С – сары, З – зәңгәр, Я – яшел)

1) КЯКСЗЗ
2) ЗККСКЯ
3) СКЯЗЯК
4) ЯЗСКСЗ

479. 1,25 Кбайт зурлыктагы файл билгеле бер тоташу аша 128 секунд дәвамында тапшырыла. Әлеге тоташу аша 250 байт күләмле файлны тапшыру өчен, ничә секунд вакыт кирәк булачак?

Җавапта бер генә сан – секундларда тапшыру дәвамлылыгын языгыз. Үлчәү берәмлеген язу кирәкми.

480. Кулланучы һәр символы 8 бит белән кодлана торган КОИ-8 кодировкасында 128 символдан торган хәбәр язган. Редакцияләгәннән соң хәбәрнең мәгълүмати күләме 1280 бит булган. Кодировка үзгәртелмәгәнен истә тотып, хәбәрнә ничә символ өстәлгәнен ачыклагыз.

1) 160
2) 128
3) 35
4) 32

481. Бирелгән кайсы *X* кыйммәте өчен түбәндәге аңлатма ЯЛГАН:

(*X* < 10) **ТҮГЕЛ ҺӘМ** (*X* < 11) **ҺӘМ** (X > 8)?

1) 8
2) 9
3) 10
4) 11

482. $2^{18}$ бит күләмле хәбәрдә ничә Кбайт мәгълүмат бар?

Җавапта бер сан гына языгыз.

483. Рәсемдә А, Б, В, Г, Д, Е, И, К шәһәрләрен тоташтыра торган юллар схемасы бирелгән. Һәр юл буенча бары тик ук белән күрсәтелгән юнәлештә бер якка гына хәрәкәт итәргә мөмкин. А шәһәреннән К шәһәренә барлыгы ничә төрле юл белән барып була?




484.  Unicode кодировкаларының берсендә һәр символга 2 байт урын бирелә. Әлеге кодировкада егерме символдан торган хәбәрнең мәгълүмати күләмен ачыклагыз.

1) 20 байт
2) 40 бит
3) 160 бит
4) 320 бит

485. Unicode кодировкаларының берсендә һәр символга 2 байт урын бирелә. Әлеге кодировкада егерме дүрт символдан торган хәбәрнең мәгълүмати күләмен ачыклагыз.

1) 384 бит
2) 192 бит
3) 256 бит
4) 48 бит

486. Бирелгән кайсы *X* кыйммәте өчен түбәндәге аңлатма хак:

(*X* > 2) **ҺӘМ** ((*X* < 4) **ЯИСӘ** (X > 4))?

1) 1
2) 2
3) 3
4) 4

487. Таблицада A, B, C, D һәм E хәрефләре белән тамгаланган биш тимер юл станциясе арасында йөк ташу бәяләре китерелгән. Таблицага тиңдәш схеманы күрсәтегез.

| | A | B | C | D | E |
|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| A | | 1 | 4 | | 1 |
| B | 1 | | | 3 | |
| C | 4 | | | | 2 |
| D | | 3 | | | |
| E | 1 | | 2 | | |




1)




2)




3)




4)

488. Эзтабардан түбәндәге шифрланган радиограмма килгән, ул Морзе әлифбасын кулланып тапшырылган:

**_ •• _ • • _ _ • • _ _ ___ •**

Радиограмма тапшырганда хәрефләргә бүленеш югалган, шулай да, радиограммада түбәндәге хәрефләр генә кулланылган булуы мәгълүм :

| **И** | **А** | **Н** | **Г** | **Ч** |
|---|---|---|---|---|
| . . | . _ | _ . | _ _ . | _ _ _ . |

Радиограмма текстын ачыклагыз.

489. $2^{23}$ бит күләмле хәбәрдә ничә мегабайт мәгълүмат бар?

Җавапта бер сан гына языгыз.

490. Өчләтә арттыручы дип исемләнгән башкаручы ике команда башкара белә, алар номерланган:

**1. 2 санын ал**

**2. 3 санына тапкырла**

Беренче команда экрандагы санны 2 санына киметә, икенче команда – 3 тапкыр арттыра.

**11 санын 13 санына** үзгәртә ала торган, 5 командадан артмаган алгоритм төзегез. Җавапта бары тик команда номерларын гына языгыз.

*(Мәсәлән, 21211 – 2 санын 8 санына үзгәртә торган алгоритм:*

*3 санына тапкырла*

*2 санын ал*

*3 санына тапкырла*

*2 санын ал*

*2 санын ал)*

Андый алгоритмнар берничә булса, аларның берәрсен сайлап алып языгыз.

491. Робот исемле башкаручы яссылыкта сызылган, шакмакларга бүленгән лабиринт буенча хәрәкәтләнергә сәләтле. Күрше шакмаклар арасында (як-якларында) стена булырга мөмкин, аның аркылы Робот үтә алмый.

Робот өчен тугыз команда бар. Дүрт команда – боерык-командалар:

**өскә аска сулга уңга**

Әлеге командаларның теләсә кайсын башкарган вакытта Робот тиңдәш рәвештә бер шакмак алга хәрәкәтләнә: өскә ↑, аска ↓, сулга ←, уңга →. Стена аркылы хәрәкәтләнергә дигән команда кабул итсә, Робот җимереләчәк.

Роботның шулай ук **буярга** дигән командасы бар, әлеге команда башкарылган вакытта Робот басып торган шакмак буялачак.

Тагын дүрт команда – шартны тикшерү командалары. Бу командалар дүрт мөмкин булган юнәлештә Роботка хәрәкәтләнү өчен, юл ачык булу-булмавын тикшерәләр:

**өскә юл ачык аска юл ачык сулга юл ачык уңга юл ачык**

Әлеге командаларны «**әгәр»** шарты белән бергә файдаланырга мөмкин, аның язылышы түбәндәгечә булырга тиеш:

**әгәр** шарт **ул вакытта**
командалар эзлеклелеге
**тәмам**
Монда *шарт* – шартны тикшерү командасы.
*Командалар эзлеклелеге* – бер яисә берничә приказ-команда.

Мәсәлән, уңда стена юклыгын ачыклап, уңга хәрәкәтләнү һәм әлеге шакмакны буяу өчен түбәндәге алгоритмнан файдаланырга мөмкин:

**әгәр уңга юл ачык ул вакытта**

**уңга**

**буярга**

**тәмам**

Шулай ук, *һәм, яисә, түгел* логик операторларын кулланып, бер шартта берничә шартны тикшерү командасын кулланырга ярый, мәсәлән:

**әгәр (уңга юл ачык) һәм (аска юл ачык түгел) ул вакытта**

**уңга**

**тәмам**

Командалар эзлеклелеген кабатлау өчен «**хәзергә**» циклын кулланырга мөмкин, аның язылышы түбәндәгечә:

**цб хәзергә** *шарт*

*командалар эзлеклелеге*

**ца**

Мәсәлән, уңга юл ачык булганда мөмкин кадәр хәрәкәтләнү алгоритмы:

**цб хәзергә уңга юл ачык**

**уңга**

**ца**

***Биремне башкарыгыз.***

Чикләре булмаган кырда озын горизонталь стена бар. Стена озынлыгы билгесез. Робот әлеге стена янында ук урнашкан өске шакмакларның берсендә тора. Роботның мөмкин булган урнашу варианты рәсемдә сурәтләнгән (робот «Р» хәрефе белән күрсәтелгән):




Робот өчен стенаның аскы ягында аңа терәлеп торган барлык шакмакларны буяу алгоритмын языгыз. Робот әлеге шартка туры килгән шакмакларны гына буярга тиеш. Мәсәлән, бирелгән рәсемдә Робот түбәндәге шакмакларны буярга тиеш:



Роботның соңгы торышы ирекле. Алгоритм ирекле киңлектәге кыр өчен, әлеге турыпочмаклы кыр эчендә төрлечә урнашкан стена өчен башкарылырга тиеш. Алгоритм башкарылу вакытында Робот җимерелергә тиеш түгел.

Алгоритм формаль башкару мохитендә башкарылырга яисә текст редакторында язылырга мөмкин.

Саклау өчен файл һәм каталог исемен Сезгә имтиханны оештыручылар хәбәр итәчәк.

492. Таблицада A, B, C, D һәм E хәрефләре белән тамгаланган биш тимер юл станциясе арасында йөк ташу бәяләре китерелгән. Таблицага тиңдәш схеманы күрсәтегез.

.

| | A | B | C | D | E |
|---|---|---|---|---|---|
| A | | 3 | 3 | | |
| B | 3 | | 2 | 1 | 4 |
| C | 3 | 2 | | 5 | |
| D | | 1 | 5 | | |
| E | | 4 | | | |

1) 


2) 


3) 


4) 


493. Эзтабардан түбәндәге шифрланган радиограмма килгән, ул Морзе әлифбасын кулланып тапшырылган:

_ • _ _ _ • _ _ _ • • • • • _ •

Радиограмма тапшырганда хәрефләргә бүленеш югалган, шулай да, радиограммада түбәндәге хәрефләр генә кулланылган булуы:

| Е | Н | О | З | Щ |
|---|---|---|---|---|
| · | _ · | _ _ _ | _ _ · · | _ _ · _ |

Радиограмма текстын ачыклагыз. Җавапта радиограммада булган хәрефләр санын языгыз.

494. Эзтабардан түбәндәге шифрланган радиограмма килгән, ул Морзе әлифбасын кулланып тапшырылган:

– – – – • • – • • – – • • •

Радиограмма тапшырганда хәрефләргә бүленеш югалган, шулай да, радиограммада түбәндәге хәрефләр генә кулланылган булуы :

| Е | Н | О | З | Щ |
|---|---|---|---|---|
| · | – · | – – – | – – · · | – – · – |

Радиограмма текстын ачыклагыз. Җавапта радиограммада булган хәрефләр санын языгыз.

495. A, B, C, D, E, F торак пунктлары арасында юллар салынган, аларның озынлыгы (километрларда) түбәндәге таблицада бирелгән.

| | A | B | C | D | E | F |
|---|---|---|---|---|---|---|
| A | | 3 | 1 | 2 | 6 | |
| B | 3 | | 1 | | | |
| C | 1 | 1 | | | | |
| D | 2 | | | | 2 | |
| E | 6 | | | 2 | | 3 |
| F | | | | | 3 | |

B һәм F пунктлары арасындагы иң кыска юлның озынлыгын табыгыз. Таблицада бирелгән юллар буйлап кына хәрәкәтләнергә мөмкин.

1) 9

2) 10

3) 11

4) 12

496. A, B, C, D, E торак пунктлары арасында юллар салынган, аларның озынлыгы (километрларда) түбәндәге таблицада бирелгән.

| | A | B | C | D | E |
|---|---|---|---|---|---|
| A | | 2 | | | 1 |
| B | 2 | | 5 | | 4 |
| C | | 5 | | 3 | 3 |
| D | | | 3 | | 4 |
| E | 1 | 4 | 3 | 4 | |

B һәм D пунктлары арасындагы иң кыска юлның озынлыгын табыгыз. Таблицада бирелгән юллар буйлап кына хәрәкәтләнергә мөмкин.

1) 5

2) 6

3) 7

4) 8

497. A, B, C, D, E торак пунктлары арасында юллар салынган, аларның озынлыгы (километрларда) түбәндәге таблицада бирелгән.

| | A | B | C | D | E |
|---|---|---|---|---|---|
| A | | 6 | 1 | 5 | 2 |
| B | 6 | | 4 | | |
| C | 1 | 4 | | 6 | |
| D | 5 | | 6 | | 2 |
| E | 2 | | | 2 | |

D һәм B пунктлары арасындагы иң кыска юлның озынлыгын табыгыз. Таблицада бирелгән юллар буйлап кына хәрәкәтләнергә мөмкин.

1) 7

2) 8

3) 9

4) 10

498. A, B, C, D, E торак пунктлары арасында юллар салынган, аларның озынлыгы (километрларда) түбәндәге таблицада бирелгән.

| | A | B | C | D | E |
|---|---|---|---|---|---|
| A | | 2 | 1 | | 5 |
| B | 2 | | 4 | | |
| C | 1 | 4 | | 1 | 4 |
| D | | | 1 | | 2 |
| E | 5 | | 4 | 2 | |

B һәм E пунктлары арасындагы иң кыска юлның озынлыгын табыгыз. Таблицада бирелгән юллар буйлап кына хәрәкәтләнергә мөмкин.

1) 5

2) 6

3) 7

4) 8

499. Компьютерда җыелган мәкалә 24 биттән тора, һәр биттә 32 юл, һәр юлда 60 символ бар. Һәр символ 8 бит белән кодлана торган Windows-1251 кодировкасында мәкаләнең мәгълүмати күләмен ачыклагыз.

1) 360 байт

2) 45 Кбайт

3) 720 байт

4) 36 Кбайт

500. Компьютерда җыелган әсәр 4 биттән тора, һәр биттә 48 юл, һәр юлда 64 символ бар. Һәр символ 8 бит белән кодлана торган KOI8-R кодировкасында әсәрнең мәгълүмати күләмен ачыклагыз.

1) 12 Кбайт

2) 12000 байт

3) 100000 бит

4) 6 Кбайт